# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын билгеләү тәртибе турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон "Сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне ваклап сатуны һәм куллануны (эчүне) чикләүләр турында" 2005 елның 7 мартындагы 11-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү тәртибен урнаштыра.

2 статья. **Сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын билгеләү тәртибе**

1. Сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннары, Федераль законны исәпкә алып, тиешле шәһәр округлары, шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җәмәгать туклануы урыннарына карата билгеләнә.

2. Сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын билгеләү өчен шәһәр округларының, шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап

сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать тукלануы урыннарын билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзи, аның составын һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

3. Комиссия составына җирле үзидарә органнарының, балалар, мәгариф, медицина, физкультура-савыктыру, спорт оешмаларының, мәдәният оешмаларының вәкилләре, шулай ук иҗтимагый оешмаларның вәкилләре кертелергә мөмкин.

4. Комиссия шәһәр округларының, шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары каравына сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннарын билгеләү буенча тәкъдимнәр кертә. Әлеге тәкъдимнәр рекомендация характерында була.

5. Комиссия тәкъдимнәре нигезендә сыра һәм аның нигезендә әзерләнгән эчемлекләрне ваклап сату, шул исәптән бүлеп сату, һәм куллану (эчү) рөхсәт ителми торган җәмәгать туклануы урыннары исемлеге (алга таба – исемлек) шәһәр округларының, шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелә. Исемлек муниципаль норматив хокукый акт белән раслана.

6. Исемлекнең формасы, аны алып бару һәм яңадан карау тәртибе шәһәр округларының, шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

3 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай эчендә җирле үзидарә органнары үз норматив хокукый актларын аңа туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 128-ТРЗ